| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.09.2023 Баулы шәһәре № 109

Баулы шәһәр Советының 2021 елның
7 апрелендәге 27 номерлы карары белән
расланган “Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре”
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставына (2022 елның 14 сентябрендәге 65 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

8 статьяның 1 пунктында:

8 статьяның 29 подпунктчасында “торак пункт территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук” сүзләрен төшереп калдырырга;

42) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә өстәмә кертергә:

«42) тирә-яктагы мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне торак пункт милкендәге җир участоклары чикләрендә урнашкан территорияләргә карата оештыру.»;

14 статьяның 4 пунктында ““Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе” сүзләрен “җирле үзидарә органнарына сайлауны әзерләүче һәм оештыручы сайлау комиссиясе белән” сүзләре белән алмаштырырга”;

15 статьясында:

5 пунктта ““Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясен” сүзләрен “Җирле референдумны әзерләүче һәм оештыручы сайлау комиссиясен” сүзләре белән алмаштырырга”;

8 пунктта ““Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе белән” сүзләрен “Җирле референдумны әзерләүче һәм оештыручы сайлау комиссиясе белән” сүзләре белән алмаштырырга”;

12 пунктта  “Сайлау комиссиясе” сүзләрен “Җирле референдумны әзерләүче һәм оештыручы сайлау комиссиясе белән” сүзләре белән алмаштырырга”;

19 статьяда:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Ачык тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат, аны уздыру вакытын һәм урынын билгеләп, шулай ук ачык тыңлауларга чыгарылачак муниципаль норматив хокукый акт проекты, ачык тыңлаулар уздырыр алдыннан 7 календарь көненнән дә соңга калмый, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында бастырылып чыгарылырга (игълан ителергә), шулай ук Баулы муниципаль районы сайтында һәм “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырылып чыгарылырга тиеш.”;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ачык тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты бастырылып чыккан (игълан ителгән) көннән алып, торак пунктта яшәүчеләр, Баулы шәһәре Мэрына ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль  норматив хокукый акты проекты яки сораулары буенча тәкъдимнәрен һәм искәртүләрен җибәрергә хокуклы, шул исәптән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да».

Тәкъдимнәрне һәм искәртүләрне җибәрү ачык тыңлаулар уздырыр алдынан ике эш көне кала туктатыла.

Баулы шәһәре Мэры килеп ирешкән тәкъдимнәрне һәм искәртүләрне гомумиләштерүне һәм ачык тыңлауларда катнашучыларга җиткерүне оештыра»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре, шул исәптән кабул ителгән карарларның мотивацияле нигезләмәсе Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында бастырылып чыгарылырга (игълан ителергә), шулай ук Баулы муниципаль районы сайтында һәм “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында, ачык тыңлаулар уздырылганнан соң 5 календарь көннән дә калмый урнаштырылырга тиеш.”;

10 пунктны  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10. Ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе, Баулы шәһәр Советы белән расланган, җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән билгеләнә”;

30 статьяда:

7 өлешнең 2 пунктының а) пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 өлешнең 2 пунктының б) пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга, “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алмаштырырга;

8 пунктта “Россия Федерациясе субъектының югары вазифаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе)” сүзләрен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алмаштырырга;

9 пунктта “Россия Федерациясе субъектының югары вазифаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе)” сүзләрен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алмаштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазифалы кешесе, муниципаль вазыйфаны биләүче башка кеше, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы “Россия Федерациясендә  җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне һәм бурычларны  үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә һәм коррупциягә каршы тору максатыннан башка федераль законнар белән, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затлардан бәйсез булган шартлар тикшерүе тарафыннан “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылa икән.»;

32 статьяның 1 пунктында “ул булмаган очракта – “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе” сүзләрен төшереп калдырырга;

33 статьяның 1 пунктындагы 12 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

40 статьяда:

1 пунктның  11) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) Баулы шәһәр Советының барлык утырышларында, алты ай рәттән, җитди сәбәпләрсез, депутат булмаган очракта»;

11 пунктчаны 12 пунктча итеп санарга;

3 пунктта “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алмаштырырга;

42 статьяда “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алмаштырырга;

46 статьяда “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алмаштырырга;

49 статьяның 3 пунктында:

тугызынчы абзацта “торак пункт территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук” сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзац белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«-тирә-яктагы мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый һәм мондый зыянны бетерүне торак пункт милкендәге җир участоклары чикләрендә урнашкан территорияләргә карата оештыра.»;

50 статьяны 8 пункт белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

“8. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы “Россия Федерациясендә  җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне һәм бурычларны  үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә һәм коррупциягә каршы тору максатыннан башка федераль законнар белән, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затлардан бәйсез булган шартлар тикшерүе тарафыннан “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылa икән.”;

58 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

63 статьяның 2 пунктында “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе сүзләрен “территориаль сайлау комиссиясе” сүзләре белән алмаштырырга”;

93  статьяны 2 пункт белән, түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

“2. Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру, “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелек) һәм муниципаль контроле турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законы белән көйләнә.”

2. Федераль законда билгеләнгән тәртиптә, Уставны теркәү өчен юстиция органына җибәрергә.

3. Уставны дәүләт теркәвеннән соң, мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар, рәсми рәвештә бастырылганнан соң, 6 статьяның 1 пунктындагы 26 пунктчасыннан кала, 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы Рәисе И.И. Гозәеров